Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«11» ноябрь 2021 ел № 5

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 8 ноябрендә, 9 ноябрендә, 11 ноябрендә узган: «2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә акча кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Авыл эчендәге юлларны, шул исәптән, сезонлы карап тоту һәм таш түшәү, төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.
2) Гәйтән авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу.
3) Гәйтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.
4) Гәйтән торак пунктында паркны төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру, территорияне коймалау һәм эскәмияләр алу).
5) Гәйтән авылы зираты территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 228 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 154 кеше катнашты.

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 132 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 22 катнашучысы тавыш бирдеНа основании изложенного, сход граждан решил:

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә акча кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Авыл эчендәге юлларны, шул исәптән, сезонлы карап тоту һәм таш түшәү, төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.
2) Гәйтән авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу.
3) Гәйтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.
4) Гәйтән торак пунктында паркны төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру, территорияне коймалау һәм эскәмияләр алу).

5) Гәйтән авылы зираты территориясен төзекләндерү”  мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева